*Без, яшь буын, бүгенге көндәге тыныч тормышыбыз өчен кемнәргә бурычлы икәнебезне онытмаска тиешбез. Чөнки без сугыш ветераннарына гомеребез белән бурычлы. Кызганыч, бу күп кенә кешеләрнең дөнья мәшәкатьләре белән исләреннән чыгып китә. Әмма ул караңгы күк йөзе астында үскән балалар безнеке кебек балачак урынына нәрсә күргәннәр икән соң? Бәлки, аларның ачы тормышлары белән танышкач, безнең йөрәкләребездә миһербанлык уяныр? Тикшереп карыйк. Сугыш чоры баласы Рәшидә апа белән булган әңгәмәне сезнең игътибарыгызга тәкъдим итәм:*



***Хәйруллина Рәшидә***

*"Әтием колхоз наряды белән урман кисеп йөри иде, шуннан кайткач безнең капка төбендә ауган койманы рәтләп ятканда, авылыбызның Җәләлетдин дигән йомышка йөрүче кешесе кәгазь тотып килде дә: "Сибгать, сине сугышка чакыралар",-диде. Шуннан әти эшләгән урыныннан бүкәнгә балтасын кадап куйды да: "Ярый",- дип кереп китте. Мин дә шунда әтигә булышып йөри идем. Без бик каты елаштык инде, шуннан әти "Еламагыз, без ул немецларны гына җиңмәскә...",-дип, безне тынычландырды. Шуннан әни шунда мунчага якты, әтинең капчыгына беренче вакытка пешереп ипиләр , киемнәр тыкты. Икенче көнне әтиләрне озатабыз инде. Бик күп белгән, таныш кешеләр белән бергә китте әти. Мин 4 айлык энекәшем Исмәгыйль белән авыл башына кадәр озаттым, ә әни районга кадәр озата барды инде. Әтине озатып кайткач бала елый, ашыйсы килә, шуннан Әминә апа дигән бер күрше апаларга алып кереп имездереп алып чыктым. Әни кич белән кайтты. Шулай, әтиебез киткәндә без әниебезгә 4 бала булып калдык. Иң олысы мин идем".*

*Тормыш әнинең хәлсез җилкәләренә калган көннән башлап, миңа иртә олыгаерга туры килде. Урак вакыты җиткәч үк, әниләрне, балалары булганлыктан, якынгарак, зират янына җибәрделәр. Мин шунда сеңелләрне ияртеп, энекәшне имезергә алып бара идем. Бервакытны шулай әни янына алып барганда, бала күпердән егылып төшеп китте. Мин бик нык куркып, баланы күтәреп алып чыгып илтеп җиткердем әни янына. Шуннан әни баланы имезеп, аннан эштән кайтты.*

*Ачлыкка килгәндә, без бик алай тилмермәдек. Бакча, азмы- күпме бәрәңгеләр бар иде. Ул бәрәңге бакчасын, 25 сутыйны кул белән казып, тырмалап, утыртып, кул белән ала идек. Бәрәңге алганнан соң өйгә кертеп салып, шуннан әкрен- әкрен чүпләп, идән астына*

*төшерәбез. Сыер бар иде. Әти киткәндә "сыерыңны бетермә, Факия. Ни генә булса да асрарга тырыш",- дип китте. Әни май атлаганда, сөт тапшырганда әзрәк безгә өлеш чыгара торган булды. Шуннан берзаман мәктәптә дә 1 тапкыр укучыларны бушка ашата башладылар. Ул бәрәңге яфрагыннан бик әче аш иде.*

*Асраган хайваныңның бәрәкәтен күрсәң, бер хәл. Заём җыйдырып тилмерттеләр ул вакытта. Йомыркасын, сөтен, барысын да тапшырырга кирәк. Яз көне май ясап илттек, аны атларга сепараторлар юк, гөбе белән атлый идек.*

*Ул елларда кышлар бик салкын килде. Өйгә икешәр тапкыр ягабыз, тәрәзәләргә саламнар кыстырып, ишекләргә икешәр кат юрган кора торган идек. Бик азапландык. Әни безне мич башына менгереп йоклатты. Үсә төшкәч, әни безне казан астына ягарга булса да дип капчык тоттырып урманга чыбык – чабыклар җыерга җибәрә торган булды. Ул вакытта керосинкалар юк. Кышка кергәндә әни я утынны сатып ала, я билет белән ала иде. Сугыш беткәч тә сугыштан кайткан ир – атлар үгез җигеп сорый торгач, утыннар алып кайтып бирәләр иде.*

*Соңыннан безне дә кружкалар тоттырып, басуга төшеп калган башакларны, борчакларны җыярга чыгара башладылар. Кружкадагы бөртекләрне арттан капчык белән җыеп йөрделәр. Фронтка әниләр оекбашлар, бияләйләр бәйләп җибәрә торган иделәр.*

*Укуга килгәндә, без 1 сыйныфка 30 бала кердек. Бу хәл сугыш башланган елны булды. Мин яхшы укыйм, матур язам, ел саен күчеп барам. Шулай итеп, 1нче сыйныфтан башлап укып килдек. 7 нче сыйныфны бетергәндә 3-4 кенә калдык, калган укучылар күчми утырып калдылар. Китаплар әз – мәз бар иде шунда.Беребездән- беребез алып торып укыдык. Олырак сыйныфларны бетереп чыгып киткәннәрдән сатып ала идек. Өйгә кайткач дәрес хәзерләргә керосиннар юк, сукыр лампа белән хәзерләдек. Якты вакытта бакча чүбе утыйсы булды.Кем белә бит, бәлки караңгы сугыш еллары тәрәзәгә какмаса, мин укуымны дәвам итеп, югары белемле дә була алыр идем, ләкин...андый авыр вакытта әниләрне, сеңелләрне, энекәшне ташлап чыгып китеп булмый. Мин ат карарга фермага төштем.*

*Пионерга кергән вакытны ачык хәтерлим. Ул вакытта вакытны бик күңелле үткәрә идек. Концертлар куеп йөрдек, дружина вожатые идем. Җырладык, биедек, мин дипломация сөйләдем.*

*Киемгә килгәндә нәрсә бар – шуны кидек. Ак бәзләр сатып алып әни шуларны буяуга манып күлмәкләр, итәкләр тегеп бирә иде. Әтинең пальто тектерегә дип алып калдырган пальто тышлыгыннан, әни миңа һәм сеңлемә бишмәт тектереп киертте. Аякка чабата, аңа күтәрмәләр куеп кия идек, язга чыккач башмакка күчтек. Ул чабата белән аяклар бик нык, үзәккә үтәрлек итеп туңды. Чүпрәккә мамык тутырып, азмы - күпме җылы булсын дип эчен сырып чабата эченә салабыз. Соңыннан, шәһәрдә яшәүче туганнар үзләреннән калган киез итекләрне кайтардылар. Шуларны ямап, шатлана- шатлана кидек.*

*Сугыш бетте дигән шатлыклы хәбәрне мәктәптә ишеттем, ул вакытта 5-6 сыйныфларда укыган вакыт. Хәбәрне ишеткәч үк, бик нык шатландык, елаштык. Авыл советы каршысына укучыларны җыеп алып менделәр, анда димонстрация оештырдылар. Бөтен авыл халкы шатланышып, елашып, көлешеп, бар дөнья белән олы шатлыгын уртаклаштылар.*

*"Соңыннан күрше йортларга әтиләре, абыйлары кайта башлады. Иң беренче булып безнең урамга Зөбәер абый кайтты. Энем Исмәгыйль аның малае Рафис белән бик якын дус иде. Рафис әтисенә әти дип йөргәнгә, Исмәгыйль дә Зөбәер абыйга әти дип йөри иде. Шуннан әни: "Улым , синең әтиең түгел ул, алай дияргә ярамый",- дигәч, энекәшем: "Безнең дә әти кайтмас микәнни инде, минем дә бик нык әти дип әйтәсем килә",- дип бик нык елады.*

*Әтидән алдарак, әтинең энекәше кайтты. Ул төнлә генә кайтып җитеп капка каккач, аны дезертир дип белеп, әни кертми торды. Шуннан төнне ул күршеләрдә үткәргәннән соң, иртә белән шакыгач кына керттек. Аннан ул абыйлар янына Казанга китеп урнашты.*

*Сугыш беткәч тә әтиләре фронттан кайткан кешеләрнең тормышлары азмы – күпме җайга китте. Безгә сугыштан соң да бик кыен булды. Бөтен авыр эш хатын- кыз һәм балалар җилкәсенә калды. Шулай да 72 тәңкә пенсия бирә башлау ярап куйды.*

*Нинди генә авырлыклар кичермәсен, кеше матурлыкка, тынычлыкка, бәйрәмгә омтыла. Сугыш беткәч тә бөтен авыл халкы елгада боз кузгалганын бәйрәм итәргә җыела иде. Анда чаналар шуып, балалар шатланышып, куанышып бөтен авыл бердәм гаилә булып язны каршыладык.*

*Сугыш вакытындагы хезмәтләр өчен, хөкүмәт "Хезмәт ветераны" таныклыгы белән бүләкләде. Ирем сугыш ветераны булганга күрә, бүгенге көндә, квартира алу бәхетенә ирештем.*

*Кадерле балаларым, исән – сау булыгыз да, тормышның кадерен белеп яшәгез. Сез бик бәхетле, матур киенәсез, тәмле ашыйсыз. Исән-сау гына яшәгез. Еллар тыныч булсын, я Ходаем. Без күргәнне сезгә күрергә язмасын.*



